**Б.К. Миннуллин**
Институт языка, литературы и искусства им. Г.Ибрагимова АН РТ, Казань

# ЛИТЕРАТУРНО-ПУБЛИЦИСТИЧЕСКИЕ ЖАНРЫ В ТАТАРСКИХ ГАЗЕТАХ НАЧАЛА XX ВЕКА

**Б.К. Миңнуллин**
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан

# XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ГАЗЕТАСЫНДА ӘДӘБИ-ПУБЛИЦИСТИК ЖАНРЛАР

(Мәкалә «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителде)

***Аннотация.*** *Начало XX века является периодом зарождения и формирования татарской публицистики. Тексты газетных статей разделяют на информационные, аналитические и художественно-публицистические. Среди текстов, опубликованных на страницах газет “Вакыт” и “Борхане таракки” и относящихся к художественно-публицистическим, чаще всего встречаются стихотворения и короткий фельетон.*

***Abstract.*** *The beginning of the XXth century is the period of the birth and formation of Tatar publicism. Texts of newspaper articles are divided into information, analytical and literary-journalistic. Among the texts published in the newspapers "Vakyt" and "Borhane Tarakki" and referring to the artistic and journalistic, most often there are poems and a short feuilleton.*

***Ключевые слова:*** *литературный язык, татарский литературный язык, язык газеты, жанры газетного текста, художественно-публицистические жанры.*

***Key words:*** *literary language, Tatar literary language, the language of the newspaper, the genres of the newspaper text, the literary-journalistic genres.*

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар милли әдәби теленең формалашуында һәм камилләшүендә аеруча мөһим бер чор булып тора. XX гасыр башында «татар вакытлы матбугаты» дигән күренеш барлыкка килеп җәмәгатьчелектә киң таралыш ала. Бүген галимнәр газета текстының жанрлар системасы турында сүз йөрткәндә, аның өч төп төргә бүленүен азсызыклый. Алар – мәгълүмати жанрлар, аналитик жанрлар һәм әдәби-публицистик жанрлар [Пельт, 1984: 8].

Әдәби-публицистик жанрлар, нигездә, көчле эмоциональ төсмергә ия, алар текст теленә, әдәби образларга, авторның чынбарлыкны тасвирлавына карата аеруча таләпчән. Шул рәвешле, әдәби-публицистик жанрларда иҗат итү – журналист осталыгының иң югары һәм катлаулы ноктасы булып санала. Әдәби-публицистик жанрларга караган материаллардагы иң мөһим сыйфат – реаль чынбарлыкта чагылыш тапкан күренешләрнең эмоциональ-образ гомумиләштерелүе һәм аларның әдәби-типик формалары. Мондый төр текстлар укучыга бер үк вакытта чынбарлыкны дөрес итеп кабул итәргә һәм тасвирлана торган вакыйгаларга карата эмоциональ мөнәсәбәт белдерергә мөмкинлек тудыра.

Бүгенге көн вакытлы матбугатында очрый торган әдәби-публицистик жанрларның төрләре, мәгълүмати һәм аналитик жанрлар белән чагыштырганда,

күпсанлы түгел: очерк, эссе, фельетон, памфлет. Кайбер галимнәр газета текстларының жанрлар системасы турында сүз йөрткәндә кабул ителгән стандарт өч төркемгә бүленеш белән чикләнмичә, киңрәк система тәкъдим итәләр. Бу исә әдәби-публицистик жанрларның составына да йогынты ясамыйча калмый: мәгълүмати жанрлар (хәбәр (заметка), отчет, репотраж), диалогик жанрлар (интервью, диалог, әңгәмә), аналитик жанрлар (комментарий, корреспонденция, мәкалә, массакүләм-мәгълүмат чараларына күзәтү), эпистоляр жанр (хатлар), әдәби-публицистик жанрлар (очерк, тасвирнамә (зарисовка), сатирик жанрлар (фельетон, памфлет, пародия, эпиграмма, эссе) [Гуревич, 2004: 20-25].

Тәкъдим ителгән мәкаләдә без жанрларның кинрәк таралган стандарт өч төркемгә бүленешенә нигезләнәбез. Шунысын азсызыкларга кирәк, тикшерелә торган «Вакыт» (Оренбург, 1906-1918) һәм «Борхане тәрәкъкый» (Әстерхан, 1906-1911) газеталарында әдәби-публицистик жанрларның барысы да урын алмаган.

Очеркта чынбарлыкны чагылдыруның логик-рациональ һәм әдәби-образлылык ысулларын берләштереп, кеше концепциясенең яисә иҗтимагый тормышның нинди дә булса аспекты хәл ителә. Гадәттә, очеркның берничә төрен аерып чыгаралар – очерк-портрет, проблемалы очерк, юл очеркы, тарихи очерк.

Эссе конкрет авторның теге яки бу мәсьәләгә карата булган, хакыйкать дип танылуга дәгъва белдермәгән, шәхси күзаллавын үз эченә ала. Функциясе һәм күләме ягыннан ул еш кына фәнни мәкалә һәм очерк белән чиктәш булып тора.

Фельетонда автор иҗтимагый тормышның тискәре күренешләре һәм чынбарлыкта урын алган тискәре вакыйгалардан кинаяләп сөйләү ярдәмендә көлә. Гадәттә мондый төр текстларда гипербола (чиктән тыш арттырып, көчәйтеп сурәтләү), гротеск (фантастик һәм көлке стильдә арттырып сурәтләү), пародия (чамадан тыш арттырып охшатып сурәтләү), литота (киметеп күрсәтү) кебек тел-сурәтләү чаралары кулланыла.

Памфлет җәмгыять тормышын характерлаган, ләкин авторның күзаллавы белән югары дәрәҗәдә туры килмәгән карашларны фаш итүгә нигезләнә. Фельетон жанрыннан аермалы буларак, памфлетның максаты – сәяси дошманны мораль яктан юк итү.

«Вакыт» һәм «Борхане тәрәкъкый» газеталарында еш кына «Фельетон» рубрикасы очрый, ләкин безнең тикшеренү күрсәткәнчә, газеталарда басылган фельетон белән әдәби-публицистик жанрларның фельетон төре арасында бернинди дә мөнәсәбәт юк. Тикшерелә торган газеталарда «Фельетон» рубрикасында басыла торган текстлар тирән анализга ия һәм көн тәртибендәге иң мөһим мәсьәләләрне яктырта, ләкин сатирик яисә юмористик төсмер алмыйлар, димәк алар «фельетон» төшенчәсенең XX гасыр башында Европа илләрендә таралыш алган мәгънәсенә туры килә һәм «аналитик мәкалә» дигәнне аңлата.

Гомумән, басылган материалга нигезләнеп сүз йөрткәндә, XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты, төгәлрәк әйткәндә, тикшерелә торган «Вакыт» һәм «Борхане тәрәкъкый» газеталары, рәсми аннотацияләрендә «әдәби газета» дигән аңлатма булуына карамастан, иң элек мәгълүмати һәм аналитик характердагы материалга басым ясый. Бүгенге көндә әдәби-публицистик жанрлар эчендә өйрәнелә торган һәм гомумән газета телендә кулланылышта булган жанрлар арасыннан «Вакыт» һәм «Борхане тәрәкъкый» газеталарында сирәк кенә булса да, кыска фельетон һәм шигырь жанрларын очратырга була.

Мисал өчен «Борхане тәрәкъкый»да «Әдәбият» исемле рубрикада басылган «Имтихан беткәч» шигыреннән өзекне карыйк. Әлеге шигырьнең ахырында «Х.М.»

инициаллары куелган.: [qaraŋğy qyš kitte inde uzdy bezdän / šäfqätle jaz qaršy čyqty ačyq jözdän / härkem maqtyj täbrik itä matur jazny / kilde inde dip qaldyrmyjča här ber süzdän...] («Борхане тәрәкъкый», алга таба – «Б.т.», «Имтихан беткәч», № 145, 1911).

«Борхане тәрәкъкый»да басылган «Матбугат» исемле шигырьдән өзекне карыйк, аның авторы Ярулла Морадов: [arzu itsen här biradär / matbuğatyŋ šöğelene / ištä kürsen küzläremez / mädänijät fiğylene...] («Б.т.», «Матбугат», № 30, 1906).

«Вакыт» газетасында, «Борхане тәрәкъкый» белән чагыштырганда, шигырь текстлары ешрак очрый. Мәсәлән, «Вакыт» газетасында басылган Зариф Бәширинең «Сабыйга» исемле шигыреннән бер өзек китерик: [ğömerneŋ iŋ küŋelle wä xozur waqyty sabyj čaqtyr, / tapsyz közge tiŋ jaman fikerlärdän xäle čaqtyr. / uenčyqlar alyp qulğa, fäqat küŋelgä salyp šunda, / ueŋ ziheneŋ usal dönja – xafasyndan bere xaqtyr...] («Вакыт», алга таба – «В.», «Сабыйга», № 488, 1909).

«Вакыт»та басылган тагын бер шигырь – Мәхмүд Мәрҗанинең «Күңлемә» дип аталган әсәре: [qajt küŋlem üz aslyŋa, ruxani bul – nurani bul! / satma qadereŋne, birmä jul dönjasyna. / sine syndyrmaq julynda, dönjanyŋ här ber eše, / ürtäsenlär, hič suzylma šul näfes qolğasyna...] («В.», «Күңлемә», № 637, 1910).

«Вакыт»та бик сирәк кыска фельетон жанры урын ала. «Борхане тәрәкъкый» газетасы белән чагыштырганда, әлеге жанрның «Вакыт»та урын алуы, аның жанрлар системасында булган аермалы сыйфаты булып тора. XX гасыр башы татар газеталарында, шул исәптән, югарыда әйтелеп киткәнчә, «Вакыт» һәм «Борхане тәрәкъкый» газеталарында, күпчелек очракта «фельетон» төшенчәсе сатирик әсәр мәгънәсендә кулланылмый, ә тирән мәгънәгә ия, зур аналитик мәкалә буларак яши. Кыска фельетонны исә, аналитик фельетоннан аермалы буларак, без әдәби-публицистик жанрлар арасына кертеп карыйбыз, чөнки биредә тормыш турында сүз бармый, ә тормыш күренешләре үзләре, еш кына көлкеле, афористик формада, сурәтләнә. Автор теге яки бу күренешкә карата булган уй-фикерләр шаукымын теге яки бу сәяси яки иҗтимагый чынбарлыкка бәйләмичә, һичшиксез дөреслеккә дәгъва итмичә укучыга белдерә, әлеге фикерләр бер-ике җөмләдән торган кыска-кыска гына блоклардан гыйбарәт. Гадәттә, кыска фельетон «Вакыт»та шул ук исемдәге рубрикада урын ала. Мәсәлән, газетада басылган берничә кыска фельетонга күз салыйк: [matur šiğyr güzäl täsvir uqydym isä hič tüzmim alam qaläm jaza bašlyjm, möhärirlek ul ni närsä! Tuqaj kebek bulasym kilä] («В.», «Нишләргә...», № 1015, 1912); [beleš tanyšlarym očrap quja ki kürmägän bulyp hič iltifatsyz ütsälär ačyq jöz telämim berdä bary šatlanasym kilä] («В.», «Нишләргә...», № 1015, 1912).

Шулай итеп, бүгенге көндә әдәби-публицистик жанрлар системасында карала торган жанрлардан, XX гасыр башы татар матбугатында, төгәлрәк итеп әйткәндә «Вакыт» һәм «Борхане тәрәкъкый» газеталарында иң киң таралганнары – шигырьләр. «Вакыт» газетасында исә, «Борхане тәрәкъкый»дан аермалы буларак, кыска фельетон жанры да очрый.

## ӘДӘБИЯТ

1. Гуревич С.М. Газета: вчера, сегодня, завтра / С.М. Гуревич. – М.: Аспект Пресс, 2004. – 288 с.

2. Пельт В.Д. Дифференциация жанров газетной публицистики: Учеб.-метод. пособие для студентов / В. Д. Пельт. – М.: Изд-во МГУ, 1984. – 48 с.